**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5360**
**07.10.2022**

Башкарма комитетның 2021 елның 29 октябрендәге 7120 номерлы карары белән расланган «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 29 октябрендәге 7120 номерлы карары белән (Башкарма комитетның 2022 елның 18 мартындагы 1438 номерлы карары редакциясендә) расланган «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлектә «Программаның бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаның бурычлары | 1. Халыкта ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуга мотивация формалаштыру һәм ихтыяри ярдәмченең уңай имиджын булдыру.<br>2. Ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм профессионализмын арттыруда ярдәм күрсәтү, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) идеяләренә һәм проектларына булышлык итү.»; |

2) 3 бүлектә «Программаның бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаның бурычлары:

1) халыкта ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуга мотивация формалаштыру һәм ихтыяри ярдәмченең уңай имиджын булдыру;

2) ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм профессионализмын арттыруда ярдәм күрсәтү, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) идеяләренә һәм проектларына булышлык итү.»;

3) 1 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 7 октябрендәге
5360 номерлы карарына
кушымта

«2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасына
1 нче кушымта

«2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ихтыяри ярдәмгә (волонтерлыкка) булышлык итү һәм аны үстерү» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралары буенча финанслау

| Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторлар күрсәткече | | | | Финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 ел база | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2022 ел мең сум | 2023 ел мең сум | 2024 ел мең сум |
| Программаның максаты: милли, социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, төрле яшьтәге гражданнарның массакүләм оештырылган ихтыяри ярдәм (волонтерлык) хәрәкәтен үстерү. | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| 2024 елга программа буенча ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегенә җәлеп ителгән 7 яшьтән 70 яшькә кадәрге халык өлеше, әлеге яшь төркеменең гомуми санының кимендә 5% | | | | | - | 3 % | 4 % | 5 % | 500 | 500 | 500 |
| 2. Халыкта ихтыяри ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуга мотивация формалаштыру һәм ихтыяри ярдәмченең уңай имиджын булдыру | | | | | | | | | | | |
| Ихтыяри ярдәм (волонтерлык) проектлары конкурсы үткәрү | | Яшьләр белән эшләү идарәсе, «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Чараларда катнашучылар саны, кеше | - | 30 | 30 | 30 | 80 | 80 | 80 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Халыкка игелек» PR-проектын үткәрү (листовкалар, буклетлар әзерләү) | Мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе; яшьләр белән эшләү идарәсе; «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Басма материаллар саны, данә | - | 400 | 400 | 400 | 20 | 20 | 20 |
| Социаль билбордлар әзерләп һәм шәһәр проспектларында урнаштырып, «Игелекле проект» социаль реклама конкурсы | Мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе; шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе; яшьләр белән эшләү идарәсе «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Билбортлар саны, данә | 2 | 5 | 5 | 5 | 50 | 50 | 50 |
| Шәһәрнең ихтыяри ярдәм (волонтерлык) хәрәкәте атрибутикасын эшләү һәм әзерләү | Яшьләр белән эшләү идарәсе «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Атрибутика саны, данә | 36 | 200 | 200 | 200 | 120 | 80 | 80 |
| 3. Ихтыяри ярдәмчеләр (волонтерлар) һәм ихтыяри ярдәм (волонтерлык) берләшмәләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм профессионализмын арттыруда ярдәм күрсәтү, ихтыяри ярдәм (волонтерлык) идеяләренә һәм проектларына булышлык итү | | | | | | | | | | |
| «Ихтыяри ярдәмчеләр мәктәбе» проектын тормышка ашыру | Яшьләр белән эшләү идарәсе «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Катнашучылар саны, кеше | - | 100 | 140 | 140 | 10 | 30 | 30 |
| Ел саен үткәрелә торган ихтыяри ярдәмчеләр форумы үткәрү | Яшьләр белән эшләү идарәсе «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Катнашучылар саны, кеше | - | 100 | 120 | 120 | 60 | 70 | 70 |
| «Елның ихтыяри ярдәмчесе» Бөтенроссия конкурсының муниципаль этабын оештыру | Яшьләр белән эшләү идарәсе «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Катнашучылар саны, кеше | - | 30 | 40 | 50 | 40 | 50 | 50 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бөтендөнья ихтыяри ярдәмчеләр көненә багышланган «Ихтыяри ярдәмчеләр көне» шәһәр чарасы үткәрү | Яшьләр белән эшләү идарәсе «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Катнашучылар саны, кеше | - | 300 | 400 | 400 | 90 | 90 | 90 |
| Ихтыяри ярдәмчеләрне транспорт грантлары белән тәэмин итү | Финанс идарәсе; яшьләр белән эшләү идарәсе; «Орион» ЯҮ МАМУ | 2022-2024 | Транспорт грантлары саны, данә | - | 100 | 100 | 100 | 30 | 30 | 30 |
| барлыгы: | | | | | | | | 500 | 500 | 500 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева